СОВЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

02.04.2025 ел Баулы шәһәре № 308

"Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Удмурт Ташлысы авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында" Татарстан Республикасы Баулы муниципаль район Советының 2021 елның 6 августындагы 75 номерлы карарын үз көчен югалтуын тану турында

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Удмурт Ташлысы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2025 елның 14 мартындагы 263/о боерыгы нигезендә, Баулы муниципаль район Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының Удмурт Ташлысы авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Баулы муниципаль район Советының 2021 елның 6 августындагы 75 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Баулы муниципаль район сайтында bavly.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

Баулы муниципаль районы Башлыгы,
район Советы рәисе И.И. Гозәеров